ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.12.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 4155**

Зеленодольск шәһәрендә транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында

Яңа ел бәйрәмнәре чаралары үткәрү кысаларында, шулай ук җәмәгать урыннарында һәм террорчылыкка каршы иминлекне тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елның 31 декабрендә Зеленодольск шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түбәндәге участокларында җәяүлеләр зонасын оештырып бәйрәм массакүләм чараларын уздыру вакытында 16.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча туктатуны гамәлгә ашырырга:

- Яшьлек урамын, Карл Маркс урамы белән кисешкәннән алып Ленин урамы белән кисешкәнгә кадәр.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча ЭЭМ бүлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- әлеге карарның 1 пункты нигезендә Зеленодольск шәһәрендә бәйрәм массакүләм чараларын үткәрүне тәэмин итү өчен барлык төр транспорт чаралары хәрәкәтен туктатуны оештырырга;
- бәйрәм чараларында катнашучыларның һәм тамашачыларның иминлеген тәэмин итү, аларны үткәрү чорында транспорт хәрәкәтен җайга салу буенча кирәкле чаралар күрергә;
- чаралар уздыру урыннарына якын булган урамнар участокларындагы оператив хәлне исәпкә алып, транспорт хәрәкәтен чикләү яки ябу буенча карарлар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин